СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

09.07.2021 г. Заинск № 69

**Зәй муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә класслы чиннар бирү тәртибе турында нигезләмә хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Расларга:

1.1. Зәй муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә класслы чиннар бирү тәртибе турында нигезләмә (1 нче кушымта);

1.2. Зәй муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә квалификация имтиханы үткәрмичә генә муниципаль хезмәтнең класслы чиннарын бирү турында тәкъдимнамәләр әзерләү тәртибе (2 нче кушымта).

2. «Зәй муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә класслы чиннар бирү тәртибе турында» 2014 елның 12 августындагы 391 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Л.Г. Ананьевага йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**